**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№ 14** **Иске Каразирек авылы** **29.12.2020 ел**

2014 елның 21 ноябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында"гы 25 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 20.11.2014 ел, № 21 карарына (23.05.2015 ел №10, 26.10.2015 ел № 6, 29.11.2019 ел № 17, 14.12.2020 ел № 12 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Салым ташламалары» турындагы 3 маддәдәге 2 бүлекнең 10 пунктчасында «торак төзелеше өчен бүлеп бирелгән һәм эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре» дигән абзацны төшереп калдырырга;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсендәге 1 өлеше нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс комиссиясенә йөкләргә.

Иске Каразирек
авыл җирлеге башлыгы: Р. Р. Вәлиев